**Нәни җиңүчеләрне котлыйбыз.**

Шушы көннәрдә Менделеев шәһәре балалар китапханәсе мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен оештырган «Смейтесь сами, посмейтесь с нами» фотоконкурсына нәтиҗәләр ясалды һәм С. Гассар исемендәге мәдәният сараенда җиңүчеләрне бүләкләү булды.

Конкурска барлыгы 140 эш кабул ителгән. Бәзәкә авылы «Ләйсән» балалар бакчасыннан әлеге конкурста 5 бала катнашты, һәм «Учение – это тяжелый труд» дип исемләнгән фотографияләре белән бертуган Азалия һәм Ясминә Зиганшиналар 2-урынны яуладылар. Нәни авылдашларыбызны һәм тәрбияче Л.М. Гилязованы җиңүләре белән чын күңелдән котлыйбыз, киләчәктә дә иҗади уңышлар, тагын да зуррак җиңүләргә ирешүләрен теләп калабыз.

Ф.Башарова




Смейтесь сами –
НАГРАЖДЕНИЯ
ДИПЛОМ
ДИПЛОМ